КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 20 апрель г.Казань № 307

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф» илкүләм проектының «Киләчәк укытучысы» федераль проекты кысаларында педагог хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын һәм квалификациясен өзлексез күтәрү үзәкләрен һәм педагогларның һөнәри осталыгын һәм квалификацияләрен бәяләү үзәген оештыру чараларын тормышка ашыру турында» 2019 ел, 02 июль, 534 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгариф» илкүләм проектының «Киләчәк укытучысы» федераль проекты кысаларында педагог хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын һәм квалификациясен өзлексез күтәрү үзәкләрен һәм педагогларның һөнәри осталыгын һәм квалификацияләрен бәяләү үзәген оештыру чараларын тормышка ашыру турында» 2019 ел, 02 июль, 534 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгариф» илкүләм проектының «Киләчәк укытучысы» федераль проекты кысаларында педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын һәм квалификациясен өзлексез күтәрү үзәкләрен һәм педагогларның һөнәри осталыгын бәяләү үзәген булдыру чараларын гамәлгә ашыру турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгын «Мәгариф» илкүләм проектының «Киләчәк укытучысы» федераль проекты кысаларында

педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын һәм квалификациясен өзлексез күтәрү үзәкләрен һәм педагогларның һөнәри осталыгын бәяләү үзәген булдыру чараларын гамәлгә ашыруның төбәк координаторы итеп билгеләргә.»;

2 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгариф» илкүләм проектының «Киләчәк укытучысы» федераль проекты кысаларында педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын һәм квалификациясен өзлексез күтәрү үзәкләрен һәм педагогларның һөнәри осталыгын бәяләү үзәген булдыру буенча чаралар комплексы («юл картасы»)»;

«Мәгариф» илкүләм проектының «Киләчәк укытучысы» федераль проекты кысаларында педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын һәм квалификациясен өзлексез күтәрү үзәкләре һәм педагогларның һөнәри осталыгын бәяләү үзәге тасвирламасы.»;

«Мәгариф» илкүләм проектының «Киләчәк укытучысы» федераль проекты кысаларында педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын һәм квалификациясен өзлексез күтәрү үзәкләрен һәм педагогларның һөнәри осталыгын бәяләү үзәген булдыру буенча чаралар комплексын («юл картасы»н) һәм «Мәгариф» илкүләм проектының «Киләчәк укытучысы» федераль проекты кысаларында педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгын һәм квалификациясен өзлексез күтәрү үзәкләре һәм педагогларның һөнәри осталыгын бәяләү үзәге тасвирламасын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгәннәр).

2. «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белемнең федераль дәүләт автономияле мәгариф учреждениесенә Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Оренбург тракты ур., 4а йорт адресы буенча урнашкан Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм һөнәри яңадан әзерләү үзәге базасында Психология һәм мәгариф институтының структур бүлекчәсе буларак «стандарт» моделе буенча Татарстан Республикасы педагогик хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын өзлексез үстерү үзәген оештырырга тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 60 көн эчендә Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Социалистик урамы, 5 нче йорт адресы буенча педагогларның һөнәри осталыгын һәм квалификациясен бәяләү үзәген булдыру буенча тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин